РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

23.03.2023 **Чистай шәһәре** № 36/1

Чистай шәһәре Башкарма комитетының
2016 елның 27 июнендәге
«Стационар булмаган сәүдә
объектларын урнаштыру
схемасын раслау турында»гы
96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, «Муниципаль милектәге җирләрдә, яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә, яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы, «Дәүләт милке чикләнгән җирләрдә, яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә, яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»гы 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарларына таянып, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 27 июнендәге «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы 96 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына, Кушымта нигезендә, 98 - 110 пунктлар белән тулыландырып, өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәре Башкарма комитетының сәүдә, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече Әхмәтова Ю.Ю. йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Чистай шәһәре Башкарма
комитетының
2023 елның 23 мартындагы
№36/1 нче карарына
Кушымта

Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/н | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты төре | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 98. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Җәмәгать туклануы | фудтрак | 2 | сезонлы |
| 99. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Җәмәгать туклануы | чатыр | 1 | сезонлы |
| 100. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Җәмәгать туклануы | Чатыр, балалар кафесы | 1 | сезонлы |
| 101. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Ял итү өчен азык-төлек булмаган товарлар | Сәүдә чатыры | 1 | сезонлы |
| 102. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Татлы мамык, попкорн | Сәүдә чатыры | 1 | сезонлы |
| 103. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Туңдырма, алкогольсез эчемлекләр | Зонт, суыткыч җиһазлар | 3 | сезонлы |
| 104. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Газеталар, журналлар | Сәүдә чатыры | 1 | сезонлы |
| 105. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Су мотоциклларын, катамараннарны вакытлыча файдалануга алу | | 1 | сезонлы |
| 106. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Балык тоту инвентарен вакытлыча файдалануга алу | Сәүдә чатыры | 1 | сезонлы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 107. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Ватрушкаларны, тимераякларны, чаңгыларны вакытлыча файдалануга алу | Сәүдә чатыры | 1 | сезонлы |
| 108. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Тир | Сәүдә чатыры | 1 | сезонлы |
| 109. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Роликларны, самокатларны вакытлыча файдалануга алу | Сәүдә чатыры | 1 | сезонлы |
| 110. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Машиналарны, велосипедларны вакытлыча файдалануга алу | Сәүдә чатыры | 1 | сезонлы |